

Безнен илдә билгеләп vтелә торган кvпсанлы бәйрәмнәр арасында Әниләр коне аерым урын алып тора. Бу конне барлык әниләргә игелек һәм кvнел жылысы, кайгыртучанлык һәм наз очен рәхмәт сvзләре янгырый. Балаларны әниләренен мәхәббәте һәм анлавы кочле итә.

Темников районы Зур Татар Карае авлында гомер итvче Садия Зәки кызы Позднякованын дvрт баласы бар. Адәм баласына килгән барлык авырлыкларны кичерә ул. Садия Зәки кызы инде олы кызынын дәвалап булмый торган авырудан vлvен кичергән, автокатастрофада һәлак булган оныгын жирләгән. Унике ел элек анын очен ин кадерле кешесе бакыйлыкка кvчә; алар 50 ел дәвамында шатлык һәм кайгы белән уртаклашып, балалар тәрбияләп vстерәләр.       Шулай да, 90 яшен тутырган Садия Зәки кызы кадер-хөрмәттә, жылылык һәм кайгыртучанлык белән әйләндереп алынган, чонки ул улы гаиләсендә имин яши. Мифтах улы Зәйдулла гына әнисенен нинди назлы куллары, нинди дорес кинәшләр биргәнен, гаиләнен һәр әгъзасы турында ничек кайгыртканын белә. Гади авыл хатын-кызынын зирәклеге каян килгәненә генә тошенә алмый.

Садия Зәки кызы vз тормышын кvз яшьләре белән искә ала. Әнисез бик иртә, Боек Ватан сугышына кадәр кала. Әтисен һәм абыйсын 1941 елда сугышка алып китәләр. Жингәннән сон әтисе кайта, ә менә абыйсын ул Белоруссиянен Гомель шәһәрендә туганнар каберлегендә жирләнгән дип таба.

Мәктәпкә, аягына кияргә бер әйбер дә булмаганга, бер кон дә йормәгәнен ул искә ала. Мәктәпсез дә чабалары бер атнага гына житәрлек була. Балалар белән әбиләре бик ярлы яшәгәннәр. Ә сугыштан сон инде яшvсмер кызга беренче сыйныф балалары белән бергә утыру оят булган. Хәзер бу хакта хатын-кыз vкenv белән искә ала, ойрәнергә кирәк иде, ди. Әмма vзлегеннән ижекләп укырга, язарга ойрәнә.

Кечкенәдән ук кул эшләренә ойрәнә: йон яулыклар, кофталар, сарык йоныннан шарфлар бәйли. Бәйләргә йонны башта ойдә чистартканнар, таратканнар, эрләгәннәр. Шул сарык жебеннән бәйләгән жылы әйберләрне базарда сатканнар. Шул акчага яшәгәннәр дә инде. Язма героебыз 12 яшендә колхозга эшкә урнаша. “Молотилканы авылда vгезләр жигеп әйләндерә иде. Шулай мин аларны камчы белән куып йортә идем, - дип сойли ягымлы Зәки кызы Садия. - Яшvсмер чагында эш коннәре очен арыш суктык, колтәләр бәйләдек, скирдалар жыйдык. Әгәр ел унышлы булса, коз коне бер эш коненә 100 грамм ашлык бирә иделәр. Әгәр уныш юк икән, эш коне бушлай vтә иде. Алабута ашадык. Ә хәзер мин ожмахта яшим!”

Язма героебыз 22 яшендә туган авылы егетенә киявгә чыга. Мифтах та әнисез vсә һәм ана яратуы һәм кайгыртусыз ничек яшәргә икәнен яхшы анлый, шуна кvрә хатынын кызгана һәм һәрнәрсәдә ярдәм итеп яши. “Бик тырыш кеше иде, - дип мактады ирен Садия Зәки кызы. Авырлыкларны vзе кvтәрде, мина бирмәде. Ир артында яшәдем. Кая гына барса да, барысын да хәл итеп килә торган булды. Ике тапкыр гына тозелдек. Әтисе һәм киявгә чыкмаган олы апасы белән бергә яшәдек. Ата-ана йортын ремонтлау һәм салам тvбәсен ябу очен, ул ярты елга урман кисvче булып эшкә барды. Ә колхозда торле эшче булып эшләде. Аннары без хәзер яшәгән бу йортны тозедек. Нигезне икәv салдык. Әкренләп тозедек”.
Садия Зәки кызынын 20 ел колхоз стажы, 4 ел торф эш-кәртvдә һәм 4 ел мәктәптә техничка булып хезмәт иткән. Гомере буе ат, икешәр сыер, бозау, сарык, vрдәк, тавыклар тотканнар. Печәнлекләр белән проблемалар булган: барысын да колхозга биргәннәр. Кыш коне vз терлекләрен ашату очен чокырлардан урак белән урып жыйганнар. Балалары кечкенәдән ук һәрнәрсәдә ярдәм иткәннәр. “Эштән әле беркем дә vлмәгән”, - дип нәтижә ясый хатын.
Бvген, олы яшьтә булуына карамастан, ул килененә һәрнәрсәдә ярдәм итәргә тырыша. “Каенана безнен оч балабызны vстерергә ярдәм итте, хужалык белән идарә итте, нәселдә олкән хатын-кыз булганга, һәрвакыт яхшы кинәшләр бирде, ә мин тынладым. Ул бик тәмле пешерә, - ди килене Талия кайнанасы турында. - Пәрәмәч, пилмән, пиццасы бик тәмле килеп чыга. Тату яшибез, бер-беребезгә хормәт белән карыйбыз”.
Менә шундый ул каенаналы-киленле тормыш. Бvгенге яшьләр vрнәк алырлык.
- Мин балаларым һәм оныкларым белән горурланам. Һәрбер ана очен аларнын балалары ин-ин яхшылар, минем очен дә бик яхшылар. Оныкларым ойдән чыгып киткәдә мине vбеп китәләр, - дип сойли Садия Зәки кызы Позднякова (анын 7 оныгы һәм 4 оныкчыгы бар). - Мин барысын да бик яратам!
Менә шунда инде ана бәхете.

**Наилә НАСЫРОВА**